# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
# МЕНДЕЛЕЕВСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
# ЕНАБЕРДИНО АВЫЛ ҖИРЛЕГЕНЕҢ КУРАКОВО ТОРАК ПУНКТЫНДА
# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ

КАРАР

22 ноябрь 2024 ел № 1

Татарстан Республикасы Менделеевск
муниципаль районы Енабердино авыл җирлегенең
Кураково торак пунктында гражданнар җыены
нәтиҗәләре турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, “Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Енабердино авыл җирлегенең Кураково торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында” Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Енабердино авыл җирлеге башлыгының 2024 елның 12 ноябрендәге 3 номерлы карары, 2024 елның 22 ноябрендә узган гражданнар җыены беркетмәсе нигезендә: җыенда сайлау хокукына ия катнашучылар исемлегенә 46 граждан кертелгән, гражданнар җыенында тавыш бирүдә катнашучылар саны 34 кеше; тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде: ”Риза” - 34 кеше, “каршы” – 0. Бәян ителгәннәр нигезендә Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Енабердино авыл җирлегенең Кураково торак пункты гражданнар җыены КАРАР КЫЛДЫ:

1. Менделеевск муниципаль районының Енабердино авыл җирлегенең Кураково авылында гражданнар җыенын узган дип санарга, җыен нәтиҗәләрен дөрес дип танырга.

2. "2025 елда үзара салымны Менделеевск муниципаль районы Енабердино авыл җирлегенең Кураково авылында яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән, махсус хәрби операциядә катнашучылардан һәм аларның гаилә әгъзаларыннан, югары уку йортларының һәм урта махсус уку йортларының көндезге бүлеге студентларыннан тыш, 1000 сум күләмендә, I төркем инвалидлардан салымны 50% ка киметеп, 500 сум күләмендә кертүгә һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге ихтыяҗларга юнәлтергә Сез ризамы?” дигән сорауны расларга

1) Урамнарны тышкы яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар астындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү, электр энергиясен тапшыру өчен билгеләнгән башка җайланмаларны ремонтлау (Кураково авылында яктырткычлар сатып алу һәм алыштыру).

2) Җир асты суларының табигый чыгу урыннарын (чишмәләрне) төзекләндерү (чишмәне ремонтлау, Кураково авылындагы чишмә территориясен төзекләндерү).

3) су белән тәэмин итү һәм су агызу системаларын, су җыю манараларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортировкалауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итә торган башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау (Кураково авылында насос сатып алу).

4) торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия автомобиль юлларын төзү ,ремонтлау, карап тоту (Кураково авылында юлларны кардан чистарту)»

3. Әлеге карарны Енабердино авыл җирлегенең махсус җиһазландырылган мәгълүмат стендларына урнаштырып халыкка җиткерергә, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга

http://pravo.tatarstan.ru һәм Менделеевск муниципаль районының рәсми сайтында « Енабердино авыл җирлеге» бүлегендә урнаштырырга http://mendeleevsk.tatarstan.ru

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Енабердино авыл җирлеге башлыгына Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Менделеевск муниципаль районы
Енабердино авыл җирлеге башлыгы Е.Ю.Скворцова